-38314



К. Иванов

# НАРСПИ



К. Иванов

# НАРСПИ

*ПОЭМА*

ТӨЗӘТЕЛГӘН ИКЕНЧЕ БАСМА

Чуваш теленнән
*Шәрәф Мөдәррис тәрҗемәсе*

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
*Матур әдәбият редакциясе*
*Казан 1958*

* * *

Редакторы
*Х. Қамалов*

Художнигы
*З. Н. Хөсәенов*

* * *

К-38 314

НАЦИОНАЛЬНАЯ
БИБЛИОТЕКА
ЧУВАШСКОЙ РЕСПУБЛИКИ

## К. ИВАНОВ ҺӘМ АНЫҢ «НАРСПИ» ПОЭМАСЫ

Чуваш халык шагыйре Константин Иванов 1890 елда Уфа губернасы Бәләбәй өязе Слакбаш авылында крестьян семьясында туа. Аның әти - әнисе бу якларга Чабаксар өязеннән бәхет эзләп килгән булганнар.

Авыл мәктәбен тәмамлагач, К. Иванов Сембер шәһәрендәге чуваш мәктәбенә укырга керә. Ул анда ахырына кадәр укый алмый: «сәяси тотнаксызлык» өчен 1907 елда мәктәптән чыгарыла, туганнары янына кайтырга мәҗбүр була. Шул вакытта Сембер мәктәбе мөдире Яковлев чуваш телендә дин һәм дәреслек китаплары чыгарырга әзерләнә. Үзе белән бергә эшләргә Ивановны да чакыра.

1908 елда Сембердә чуваш халык риваятьләре җыентыгында К. Ивановның беренче әсәрләре: «Тимер талкы», «Ике кыз», «Тол хатын» дигән экиятләре һәм «Нарспи» поэмасы басыла. Шул ук елларда Иванов шагыйрь М. Лермонтовның «Купец Калашников турында җыр», «Болытлар» һ. б. әсәрләрен чуваш теленә тәрҗемә итә.

1909 елда К. Иванов укытучы исеме алу өчен сынау үтә. Ләкин аның сәламәтлеге начарланганнан-начарлана бара. Тизрәк терелеп, яңадан иҗат эшенә керешергә уйлый. Әмма аның теләкләре тормышка ашмый, ул бик каты авырый башлый. 1915 елда, әле 25 яшькә дә җитмәгән хәлендә, үлеп китә.

Шулай кыска гомерле булуына карамастан, К. Иванов чуваш халкы тормышында тирән эз калдыра, үз халкының поэзиясенә беренче нигез ташлары сала.

К. Ивановның әдәби эшчәнлеге 1905 елгы революциядән соң хөкем сөргән кара реакция елларына туры килә. Бу исә аның иҗатына зур тәэсир итә, Иванов

халык белән бергә яши, тормыш авырлыгын аның белән бергә күтәрә, кече яшьтән үк социаль тигезсезлекне татып, аңа нәфрәт белән карый.

«Нарспи» поэмасы социаль тигезсезлекнең кешеләр тормышына китергән авыр трагедиясен сурәтли. Акча, байлык җирдәге бөтен нәрсәне буа, үзенә буйсындыра. Кешенең иң кокатдәс хисләрә, кешеләр арасындагы матур мөнәсәбәтләр шул байлык, акча астында таптала. Бу шундый заман:

Атасы ашый кыз башын,
Туган ашый туганын.

Гүзәл кыз Нарспи Сәтнәр исемле ярлы егетне сөя. Алар кичке уеннарда очрашалар, аңлашалар. Төрле хыяллар коралар. Әмма аларның теләкләрен бу тормышның каты «законнары» җимерә. «Черегән бай» Михәдәр үзенең чибәр кызын — Нарспины икенче авылдагы бер бай кешегә — Тохтаман картка ярәшә. Нарспи төне-көне кан-яшь түгә башлый. Бердәнбер таянычы булган сөйгәне Сәтнәргә барып сыена, аннан ярдәм сорый:

Дошман бик усал, диләр,
Ничек аннан котылыйм?
Сәтнәр, Сәтнәр, әйтче син,
Кая китим, ни кылыйм?

Ә Сәтнәр, ярлы егет, ни эшли алсын инде! Аннары ул йомшак характерлы, кыюсыз. Нарспига әйткән җавабында да шул сизелә:

Ул дошманны бетерер
Көчле куллар миндә бар.
Ләкин аны юк итсәм,
Аннан усал дөнья бар!..

Шулай да Сәтнәрнең икеләнүе, Нарспи тәэсирендә, әкренләп бетә, мәхәббәт барысын да җиңә, алар икесе бергә урманга качалар.

Ләкин аларны тотып алып кайталар. Нарспины ирексезләп Тохтаманга кияүгә бирәләр. Шагыйрь аның бу моменттагы авыр кичерешләрен бик образлы, җан әрнеткеч итеп ачып бирә:

Кырда сабан астында
Чирәм чырт-чырт киселә.
Зәһәр кайгы-сагыштан
Нарспи җаны өзелә...

Шулай да Нарспи язмышка буйсынырга теләми. Ул кыю карарга килә. Ә Сәтнәр, барыбер, буйсынучан характерлы булып кала. Ул Нарспи белән Тохтаман туенда була, кияү белән кызны келәткә ябып куйганнарын күреп тора, ләкин бертөрле дә чара күрми. Ә Нарспи түзеп торырга теләми. Ничек кенә булса да котылу чарасын эзли:

Юк, үз башым беткәнче,
Дошманымны юк итәм.
Газап күреп түзгәнче,
Тохтаманны... юк итәм!

Нарспи Тохтаманны агу эчертеп үтерә дә үзенең мәхәббәте Сәтнәр белән кушыла.

Нарспи образы бик матур, саф вөҗданлы, каһлаулы кичерешләргә бай натура итеп бирелә. Тохтаманны үтергәч, ул бик нык кайгыра, вөҗданына тап төшкән кебек тоя. Бу исә хатын-кыз күңеленең йомшак, нечкә булуын аңлата. Нарспига Тохтаманның шәүләсе эзәрлекләп йөри кебек тоела.

Шунда ләкин кара кош
Чинап куйды бер заман:
Нарспи җанын эзли гел,
Ай, Тохтаман, Тохтаман...

Нарспиның шулай газаплануы аның дингә, хорафатка ышануыннан гына түгел, ә аның җанының сафлыгында, аның күңеленең, акылының һәртөрле түбәнлекләрдән, пычраклыклардан өстен булуында. Ул башкалардан шуның белән аерылып тора. Ул чынлап та бу «караңгы патшалыкта» ялтырап киткән кояш нуры...

Поэма дастаннарга хас формада язылган, чуваш халык иҗатына бик якын тора. Әсәр художество алымнарына гаять бай, күп кырлы. Әсәрдә сурәтләнгән образлар үзләренең үзенчәлекле билгеләре белән күз алдына килеп баса. Михәдәр — бай, һәрвакыт хаким-

лекне ярата. Аның карчыгы шулай ук кешелексез — акча колы, үзенең туган кызыннан баш тарта. Тохтаман — тәкәббер, масаючы, ахмак кеше, аның байлыгы гына аны кеше итеп күрсәтә.

К. Иванов үзенең «Нарспи» поэмасында социаль тигезсезлекнең искиткеч фаҗигаләрен сурәтләп бирә. Иске дөньяның кешеләрен коточкыч изүен, җәберләвен ачык картиналарда тасвирлый. Ләкин автор шул «усал дөнья»дан ничек котылу юлын күрсәтми.

* * *

Татар укучыларына тәкъдим ителә торган бу поэма шагыйрь Шәрәф Мөдәррис тарафыннан чуваш теленнән тәрҗемә ителә. Тәрҗемәнең беренче басмасы 1942 елда ук басылып чыккан иде. Хәзер Ш. Мөдәррис аны яңадан тәрҗемә итте. К. Иванов әсәренең бөтен матурлыгын татар укучыларына җиткерү өчен күп көч куйды.

*Х. КАМАЛОВ*

## 1. СИЛБИ АВЫЛЫНДА

Ямьле Буш[1] ай ахырында,
Кояш карый яктырак;
Силби — чуваш авылында
Кар да эри яхшырак.
Таулар, үрләр кап-кара,
Кары тәмам киткәнгә.
Чыга чирәм куп-куе,
Кояш нурын сипкәнгә.
Суык, усал кыш китә,
Китә елап, тавышлап;
Елый бозлы яшь белән,
Үткән көнен сагышлап.
Сулар ташый, гөр килә
Чокырларда, тугайда.
Ләкин күпме елама —
Кояш — кызу шулай да!
Кыш, шау килеп, бар җирне
Күз-яшь белән юганда —
Бала-чага, уйнап гел,
Чабып йөри урамда.

---

[1] Буш ай — элек чувашларда яз ае, «эштән буш» ай. Хәзер март аена туры килә. (*Тәрҗемәче.*)

Килде матур, юмарт яз,
Килде бөркеп җылысын.
Кояш көлә, дөньяның
Куып кышкы йокысын.
Кара урман җанлана,
Яшел кием киенә.
Буш кыр инде яшәреп,
Яме белән сөенә.
Төрле-төрле чәчәктән
Тәмле хуш ис бөркелә.
Бар җирдә дә кошларның
Матур җыры гөр килә.
Күктә, болыт артында,
Җитез тургай җыр суза.
Йомшак үлән өстендә
Бәрән-сарык пыр туза.
Шунда, көтү янында,
Ыргы уйный бер бала.
Карыны ачкач, Силбигә
Күзен текәп, моңлана.

---

Силби авылы — бай авыл,
Тора урман алдында.
Кантур[1] төсле шәп өйләр
Биек таллар астында,
Читән — авыл тирәсе,
Яшел чыбык читәне.
Бакчаларда, ындырда
Узган елның кибәне.
Зур урамда өйләрнең
Башы сары тактадан.
Сул якта да, уңда да
Хуш ис җөелә бакчадан.

---

[1] Янәсе, контора төсле зур һәм матур өйләр.

Каралтылар, коймалар
Таш дивар күк! Күр әле!
Матур сары капкалар
Челтәр-челтәр түбәле.
Силби авылы — зур авыл,
Ерактан нәкъ бер шәһәр!
Ахры, монда, чуашта,
Мал күп, дисең, шулкадәр!

---

Гөрләп ага бер елга
Бу зур авыл читендә.
Кояш, бизәк бизәкләп,
Уйный саф су битендә.
Тоных, саф су астында
Күксу болыт чайкала.
Карт тал суга баш ия,
Үзен күреп шатлана.
Менә күпер. Бер бабай
Суга кармак төшерә,—
Уттай җитез балыклар
Хәлне ләкин төшенә!
Әнә анда балалар
Бата-чума чабалар,
Балык тотучы картны
Үчекләргә баралар.
Әнә берәү күпердән
Аръякка узып бара.
Елга аша чыкты да
Китте урманга таба.

---

Оҗмах кебек диярсең
Чуваш авылы — Силбидә.
Шат күңелле кешеләр
Көн үткәнен сизми дә.

Адәм тавышы, кош җыры
Тирә-якка тарала.
Язгы матур көн җыры
Яңгырап тора һавада.
Албутмыни, кешеләр
Урам буйлап баралар!
Өй артында, шаулашып,
Уйный шаян балалар.
Нар[1] күк сылу яшь кызлар
Аккошлар күк үтәләр.
Чылдыр-чылдыр тәңкәләр
Нурда җем-җем итәләр.
Җир җимертеп, егетләр
Бии капка алдында, —
Тормыш матур, аһ, матур
Олы Силби авылында!

---

Нәрсә көчле кешедән
Шушы якты дөньяда?
Тик ул гына чын хуҗа
Җирдә, суда — кайда да.
Тик шул көчле кеше дә
Дөньясына баш ора,—
Акча белән эчемлек
Акылыннан яздыра.
Бөек калым-атнада [2]
Кайсы чуваш эчми соң?
Тирән нәүрәц эчендә
Күпме сыра бетми соң?

---

[1] Н а р — легендар образ, матурлык, сәламәтлек, тазалык символы. «Нарспи» исеменең «Нар» белән башлануы да моңа бәйле булса кирәк. Гомумән, Иванов үзенең поэмасында христиан исемнәрен алмый.

[2] К а л ы м а т н а с ы — мәҗүсилектән калган язгы бәйрәм. Бер атна буе сузыла.

Ашадык та, эчтек тә,
Җырлаштык та биештек.
«Шуннан башка бәйрәмең
Бәйрәммени?» — диештек.
Көн үтә дә, урамда
Арта һаман исерек.
Кичке шау-шу урманга
Барып керә ишелеп.

---

Эчә-эчә кичкырын
Чуваш арый, күбенә.
Ял иткәндә балчык та
Түшәк булып күренә.
Ята чуваш албут күк,
Белми кайда торганын.
Бөтен урам буйлата
Суза үзенең җырларын:
— Күп эшлә дә күп аша,
Каты тирлә, каты эч!
Эш кешесен кем тиргәр?
Эчү — аның хакы ич!
Вакыты белән эшлибез,
Вакыты белән эчәбез.
Өйдә сыра булмаса,
Күршеләргә керәбез.
Күршеләрдә булмаса,
Әйрәнен дә эчәрбез.
Әйрәне дә булмаса,
Туры[1] бирер, көтәбез!

---

Калым үтә, кар бетә,
Җитә язгы сабан да.

[1] Туры — тәңре, алла.

Чуваш бик тиз айнымый,
Махмыр бетми һаман да.
Инде, исерек чувашлар,
Вакыт сезгә торырга!
Биек үрләр ямь-яшел,
Сулар бетте болында.
Әй агайлар, торыгыз,
Тирә-якка карагыз!
Сукагызны рәтләгез,
Әзер булсын арбагыз!
Салкын суда юынсаң,
Биткә-күзгә төс кертер,
Яхшы итеп ашап-эч —
Язгы эшкә көч кертер.
Атны тизрәк җигегез,
Язгы эшкә чыгыгыз! —
Әй бер тәңрем, саулык бир,
Уңыш бирсен кырыбыз!

## 2. ГҮЗӘЛ КЫЗ

Яшел чирәм арасында
Сап-сары чәчәк үсә,
Силби — чуваш авылында
Нарспи атлы кыз үсә.
Бите-күзе бик чибәр,
Кырда сары чәчәк күк[1].
Ике күзе чем-кара,
Ике кара сәдәп күк.
Озын толым — бөдрәле,
Җем-җем уйный тасмасы.
Атлап-атлап барганда,
Чыңлый көмеш тәңкәсе.
Күзе белән бер бакса,
Егет күңле яктыра,
Нечкә ирене бер көлсә,
Егет җаны ашкына.
Кырда сары чәчәкне
Кемнәр өзелеп сөймәс соң?
Шундый матур кыз өчен
Нинди егет көймәс соң?

---

[1] Сары чәчәк — чувашларда сары төс — иң матур төс булып, чибәрлек символы булып санала. Оригиналда бу бүлекнең исеме дә «Сары кыз» дип бирелә.

Кояш иңәр-иңмәстән
Кат-кат юына, бизәнә.
Әйлән-бәйлән уйнарга
Чыгам, ди дә кинәнә.
Җилкә аша төшенә
Хәситәсен төшерә.
Кызыл ефәк шәл дә бик
Килеш тора төсенә.
Аның тавышы бик матур,
Кош җыры дип уйлыйсың.
Яңгыратып бер көлсә,
Бик таза кыз ул, дисең.
Сөенеч бирә җырлары
Әйлән-бәйлән беткәнче;
Чулпан йолдыз биектән
Җем-җем нурын сипкәнче.
Әткәсенең йортында
Тыныч йоклый шат бала.
Матур-матур төш күреп,
Төшендә дә шатлана.

---

Иртүк тора, киенә,
Күңлен эшкә бирә ул.
Я ефәк җеп ала да
Җырлый-җырлый чигә ул.
Я ул башлый җөйләргә,
Җөен тигез, тиз тезә,—
Сүс койрыклы корыч эт
Бер чыга да бер керә.
Я ул, суса уйнатып,
Киндер суга бервакыт.
Я ул тора уйланып,
Шүреләргә җеп катып.
Яки мәче сәкедә
Битен юса,— сиз генә!—

Кунак өчен җитез кыз
Аш-су карый тиз генә.
Яхшы үтте тормышы
Яшькә-буйга җиткәнче.
Җиде яттан яучылар
Өткәсенә килгәнче.

---

Михәдәр күк черегән бай
Юктыр тирә-якта да.
Ярата ул үз кызын,
Аның белән мактана:
— Минем кыз күк кемдә бар,
Кемдә андый хур кызы?
Юкмы читек-кәвеше,
Юкмы көмеш чулпысы?
Силби авылы гомер дә
Андый кызны күрмәстер!
Бер чуваш та үз кызын
Михәдәр күк сөймәстер!
Михәдәргә ни җитми?
Ниләр юк соң милкемдә!
Көмеш тәңкәм, киндерем
Аз дип әйтмәс һичкем дә!
Келәт тулы игенем,—
Саныймыни барын да?
Май, сөт-катык, сыра-бал
Азмыни соң базымда?

Дөрес сүздә алдау юк:
Анда байлык никадәр!
Аңардан бай кайда бар?
Авылда бер — Михәдәр!
Аның йорты кала күк,
Җил дә керә алмаслык.

Каралтылар бик биек —
Тавык менә алмаслык.
Йорты тулы әйберләр,
Бөтен җирдә мал-милек.
Келәт-келәт игеннәр,
Абзар тора шау килеп.
Аргамактай шәп атлар
Солы, печән ашыйлар.
Терлекләре бик симез,
Мичкәләргә ошыйлар.
Тури гаста[1] шул бай өй
Әллә каян күренә.
Ышанасың, мактанса —
Михәдәрнең сүзенә.

---

Шул яхшы бай Михәдәр,
Кызын чиксез яратып,—
Масленица узгачтын,
Куйды иргә ярәшеп.
Булыр туйны авылда
Көтә бар да түземсез:
— Шул ике бай берләшсә,
Туй шәп булыр, күрерсез!
Симек[2] кайчан җитәр соң?
Ничек шунча чыдыйк соң?
Симек көне җиткәнче
Ничек көтеп торыйк соң?
Михәдәрнең йортында
Бирнә-фәлән тегәләр;
Туй гайрәтен сизенеп,
Бар көчләрен түгәләр.

---

[1] Тури гас — югары оч, таудагы урам, авыл очы.
[2] Симек — язгы бәйрәм. Бер атна буе бара.

Ләкин Нарспи йөрәген
Туй кайгысы газаплый.
Яшерен-яшерен яшь түгеп,
Сәтнәр исемен кабатлый.
Кеп-кечкенә бер өй бар
Авыл чите — Тугаста,[1]
Карчык әнкәсе белән
Сәтнәр тора бу башта.
Чибәр егет Сәтнәрдә
Аргамактай бер ат бар;
Карчык әнкәсе бар да
Кайнар канлы йөрәк бар.
Көн-төн байга эшләргә
Көчле ике беләк бар;
Дошманнарын җиңәргә
Уттай үч һәм теләк бар.
Аннан башка Сәтнәрдә
Юк кына шул берни дә.
Ярлы, диеп, Михәдәр
Кызын аңар бирми дә!
Безнең Нарспи, гүзәл кыз,
Бик сөя шул Сәтнәрен.
Туй булганга кайгырып,
Түгә хәзер яшьләрен.

---

Биек улак каршына
Талдан күләгә төшә.
Көн дә иртән шушында
Сәтнәр Нарспиен көтә.
Көтә-көтә күп тора,
Җитез атын сугарып.

---

[1] Тугас — «Тури гас»ның кыскача әйтелеше. Алдагы исемнәрне кара.



НАЦИОНАЛЬНАЯ БИБЛИОТЕКА
К-38314
1844

Нарспи килә таң-иртә,
Чиләк тотып, суга дип.
Нарспи атлый, кулында —
Шалтыр-шолтыр чиләге.
Шатлык белән Сәтнәрнең
Дөп-дөп тибә йөрәге.
Нарспи атлый, еректан
Кояч йөзе яктырып.
Биек улак башында
Сәтнәр тора ашкынып.
Елтыр-елтыр күзләре
Гүзәл кызга багалар,
Сары мыек астыннан
Җылы сүзләр тамалар.

## 3. СИМЕК КИЧЕ

Челтер-челтер су ага
Биек улак буйлата.
Ялтыратып көмеш күк,
Суын кояш нурлата.
Көмеш-мәрҗән такыялы
Матур кызый су ала.
Сөйли-сөйли яшь егет
Җитез атын сугара.
Биек талда яшеренеп,
Бер кош җырлый моң гына.
Чапкын аты эчкәндә,
Егет сөйли тын гына:
— Шулай ук соң, Нарспием,
Тәкъдирдәге җитәрме?
Шулай сине ят җиргә
Явыз алып китәрме?
Ах, бәхетем юктыр шул,
Әткәң-әнкәң бик бай ла...
Бай булгач та, ярлыдан
Йөзне чөерү бик җай ла...

---

— Үпкәләшмик, Сәтнәрем,
Ни хәл генә итим соң?

Шул бай эти-энидэн
Кая качып китим соң?
Эти-эни ахмак шул,
Бүтэн юатыр сүзем юк.
Ни хэл итим, әйтче син?
Җаен тапмый түзем юк.
Кояш иңгэч, кич булгач,
Этием эшен башкара:
Хушылка[1] бае белэн
Минем туем башлана.
Дошман бик усал, дилэр,
Ничек аннан котылыйм?
Сэтнэр, Сэтнэр, әйтче син:
Кая китим, ни кылыйм?
Сине бигрэк яратып,
Сөеп гомер сердем мин.
Тик барыбер бу көнне
Яшь башымнан күрдем мин...

---

— Кайнар канлы йөрэгем,
Бердэнберем — башым бар;
Тагын карчык энкэм бар,
Аргамактай атым бар.
Барысыннан яхшырак —
Син, сөйгэнем, ярым бар.
Лэкин сине дэ бүген
Тартып алыр залим бар.
Ул дошманны бетерер
Көчле куллар миндэ бар.
Лэкин аны юк итсэм,
Аннан усал дөнья бар.
Син телэсэң, шул атта
Яныңа килеп җитэрмен.

---

[1] Хушылка — авыл исеме.

Сине алып, еракка
Очармын да китәрмен!
— Сәтнәр, бар кит, син ашык,
Суга төшә бер хатын...
Сизмәдемме сөйләшеп,
Аерыласым бер дә соң?..
— Сау бул инде, Нарспием,
Бичараңны уйда тот!—
...Ат «ялт» итеп сикерде,
Очты, тузан уйнатып.
Нарспи тирән кайгыда,
Карап калды туйганчы.
Кузгалмады урыныннан
Ярын күздән җуйганчы.
— Сау бул инде, хуш инде,
Ничек синсез калыйм соң?
Синең белән булмыйча,
Ничек ятка барыйм соң?
— Нидән, Нарспи, син моңсу?
Кияү картмыни, җаным?
Әллә бирнәң бик азмы?—
Диде әлеге хатын.
Нарспи суын алды да
Өйгә китте моңсынып;
Өйгә җитте, яшь түкте,
Сәтнәр өчен борчылып.

---

Өйдә карчык пыр туза,
Эш күп, имеш, никадәр!
Сипли тышта бер ялгыз
Туй күмәсен [1] Михәдәр.

[1] Күмә — көймә, өсте ябулы бизәкләнгән арба, кибетка. Тантаналы йөрешләрдә, туйларда файдаланылган.

Кызы өчен эшли карт
Балта белән шак та шок.
Аның бөтен битеннән
Тама тире тып та тып.
— Кече яшьтән үстердем,
Буйга җитте, зур инде!
Хәзер сөйгән кызыма
Соңгы эшем шул инде!
Үсеп җитте, кыз булды,
Кияү маллырак кирәк.
Киявен дә таптык та,
Күмә җайлырак кирәк.
Җитте инде симек тә,
Кызым туен ясарга,—
Кардәшләрем җыелса,
Бүген туен ачарга!..

---

Михәдәрдә сыра күп —
Мичкәләре быгырдый.
Бөтен кардәш-туганның
Тамак төбе кымырҗый.
Ике зур мич эчендә
Төрле ашлар парлана.
Бөтен кардәш-туганның
Авызы-ирене майлана.
Кара өйдә шыбырчы [1],
Шыбырын тотып тора.
Тышта егет-җиләннең
Табаны кычып тора.
Көтеп туйның рәхәтен,
Очып йөри барысы да.

---

[1] Шыбырчы — милли музыка коралы шыбырда уйнаучы. Шыбыр үгез карынынннан ясала, эчендәге һава киселеп тышка чыкканда, музыкаль авазлар бирә.

Өйдә бер җан газабын
Сизми ләкин кайсы да.
Нарспи утыра келәттә,
Коймак майлый тын гына.
Бу туй аңар кайгылы,
Биреп тора шом гына.

---

«Җиде яттан килде ят,
Килде әткәм каршына.
Мин яшь кызны бирделәр
Җиде ятның картына.
Әткәй, әнкәй, туктагыз,
Тагын бер ел көтегез!
Мин — бердәнбер кызыгыз,
Тагын бер ел тотыгыз!
Әткәй-әнкәй исрекләр,
Минем хәлгә кермиләр,
Кияү бик бай диләр дә
Минем җанны белмиләр».
Әй карт җан да каты җан! —
Катып киткән киез шул!
Әй яшь җан да нәни җан —
Йомшак булуы тиеш шул!
Җаны булса кош җаны —
Елар да көләр иде,
Булса икән канаты —
Очар да китәр иде!..

---

Кояш төште кызарып,
Кара урман артына.
Кәтү төште гөр килеп,
Олы Силби авылына.
Әнә анда яшь кызлар
Сыерлар куып чаба.

Чая матур егетләр
Йөгерә шунда таба.
Әнә чаба бер адәм,
Ала сыеры мөгрәнә.
Ахмак чучка чиный да
Бөтен авыл тетрәнә.
Көтү узгач, урамда
Кара тузан кузгала.
Атлый менә бер карчык,
Аннан тагын туктала.
Менә сыңар кул белән
Тотты сыра бадьясын:
— Ай-һай, авыр күтәрү,
Ай-һай, эчү җай да соң!

---

Туйга дәшә Михәдәр,
Килсен, имеш, барлыгы.
Сыра тотып, тузанда
Атлый аның карчыгы.
Кардәш-дуска керә дә
Ачып куя сырасын,—
Туйга дәшеп эчертә,
Үтәп бөтен йоласын.
— Якын кардәш-туганнар!
Безне санга саламсыз?
Кызны иргә бирәбез,
Тури-гаска барамсыз?
— Барабыз без, барабыз,
Бармый-нитми калмабыз!
Алла бирсә, сау булсак,
Сүзең кире какмабыз!
Карчык йөри авылда,
«Кич җитте» ди, хәтерләп.
Карчык йөри өендә
Ипи-тозын хәзерләп.

---

— Якын кардәш-туганнар,
Тури-гаска юл алыйк!
Бәрәкәтле сырасын
Эчә-эчә куаныйк!
Безнең туган кыз бирә,
Безне туйга чакыра;
Җир җимертеп туй ясый
Сөйгән кызы хакына.
Иске чуваш йоласын
Туй башында карарбыз:
Борынгылар рухына
Ипи-тозын кабарбыз.
Карт әбиләр, бабалар,
Шат торыгыз җәннәттә.
Безнең ипи-тозыбыз
Булсын сезнең дәүләттә!
Безнең сөйгән Нарспига
Яхшы тормыш бирегез:
Аның бәхет-шатлыгын
Саклый гына күрегез!

---

Искә алгач картларны,
Хәер-дога, теләктә,—
Аннан туйны башларга
Җыйналдылар келәткә.
Ата-ана бер чүмеч
Сыра тотып сүз ката.
Ата-ана яшь кызның
Күз яшьләрен кузгата.
— Нарспи кызым, шул сиңа:
Әйбәт кенә йөр инде.
Ирең какма, яхшы тор,
Тату гына тор инде.
Тыңла аны, юаш бул,
Дошман әйтсә — сыгылма.

Эшне эшлә, эшчән бул,
Юк-бар эшкә тыгылма!—
Ата-анасы вәгазьли,
Кыз күзеннән яшь тама.
Шыбыр тавышы яңгырый,
Инде туй да башлана.

---

Силби авылы хырылдый,
Йоклый бар да үлгән күк.
Күреп дөнья тынлыгын,
Ай да сөенеп үткән күк.
Кереп бетте уеннан
Кызлар, егет-җиләннәр.
Инде йоклый туй халкы,
Йоклый хуҗа дигәннәр.
Җылы һаман суына,
Ишетелми аваз-өн,
Бер эт өрә, иренми—
Ничек ачкан авызын!
Әтәч йокы аралаш
Тавыш бирде моң гына.
Инде урман артына
Ай да бата тын гына.
Тыныч, татлы йокыга
Чуваш талды. Тик менә
Шул кич газап эчендә
Бер яшь йөрәк тилмерә...

## 4. ТУЙ

Кояш чыгар-чыкмас ук,
Төтен күккә юл сала.
Күзне ачар-ачмас ук,
Чуваш утыра мунчада.
Симек йоласы белән
Юына яше-карты да.
Симек чирәме белән
Тәнен ышкый барсы да.
Борынгылар калдырган
Гадәт шулай саклана.
Шулай бүген чувашлар
Мунча кереп сафлана.
Чыкты барсы иртәнчәк,
Өс-башларын яңартып.
Китте барсы туйга дип,
Урам буен яңратып.
— Әнә туй да менә туй!
Шушы безнең туй ласа!
Тури-гаста туй тавышы
Ярты авылны кузгата.

---

Михәдәрнең йорт-җире
Ерактан дәшеп тора.

Урам-капка төбендә
Кешеләр басып тора.
Кем керә дә кем чыга —
Туйны карарга килгән.
Карт-коры да аз түгел,
Сыра кагарга килгән.

Биетеп тә сикертеп,
Яңрый шыбыр тавышы.
Яхшы хуҗа кушканга
Туй гөрләтә барысы.
Туй итә дә туй халкы
Арый, ләкин шатлана.
Шыбыр тавышы басылгач,
Туй җырлары башлана:
— Ник соң тыныч торасыз?—
Туйның йоласы түгел.
Без бит тыныч торырга
Былбыл баласы түгел!

---

Ләкин шыбыр холыксыз:
Һаман биергә дәшә.
Дөбер-шатыр биюдән
Өйләр селкенә ләсә!
Түрдә өлкән кунаклар —
Күп эчсә дә — җирендә!
Яхшы теләк телиләр
Кияү белән киленгә:
— Кыз да кияү сау булсын,
Бала белән шат булсын!
Матур, тату көн күрсен,
Усал сүздән сак булсын!
Ашыйк-эчик, туганнар,
Бергә үтсен гомерләр!
Әйдә, шәбрәк туй итик,

Күтәрелсен күңелләр!
Менә инде, күр инде,
Хуҗа ничек сиптерә!
Кыз туенда шатланып,
Картлыгында типтерә!

---

Матур кияү-егетләр
Бөтен өйне селкетә,
Кызлар тагын үзләрен
Такмак әйтеп җилкетә.
Ефәк чигүле чаршау
Җил-җил килә, сырлана.
Кызыл чаршау артында,
Бөркәнчектә — кыз бала.
Кыз елый да яшь белән
Бөркәнчеге таплана.
Дус кызлары җырына
Аның тавышы каплана.
Дус кызлары җырлыйлар,
Нарспи диеп сызланып;
Михәдәрнең Нарспиен
Бу туй өчен кызганып.
— Бер чал сакал Тохтаман
Кияү булып киләчәк.
Җаны сөйгән ярыннан
Яшь кыз ерак китәчәк.
Әгәр ятка китсәң син,
Сәтнәр ни хәл итәр соң?
Сылу Нарспи, әй апам,
Бәхетең кайда икән соң?»

---

Җир җимертеп туй бара—
Очы-кырые җитәрме?
Кардәшләргә йөриләр,
Илдә кардәш бетәрме?

Зур күн күмэ Нарспины
Йөртэ кардәш-туганга.
Дус кызлары сузган җыр
Барып сеңэ урманга.
Көнен-төнен уйнарга
Шыбыр һич тә тарсынмас.
Көнен-төнен биергэ
Егетләр дә тартынмас.
Бала-чага бер көтү
Туй күмәсе артында.
Үлек күк бер карт кеше
Калгый койма астында.
Туй бара да шәп бара,
Карт кешенең гаме юк.
Бии яткан җирендә
Торыр иде — хәле юк.

## 5. БАГУЧЫ ЯНЫНДА

Нәни генә кара йорт,
Сәкедә карт, чал чәчле.
Якты керми бераз да,
Тәрәз нәни шулхәтле!
Өйнең эчен яктырта
Тик ачык ишек кенә.
Идән буйлап кояшның
Нурлары шуып керә.
Картлач түрдә утыра,
Ямый-ямый чабата,
Аяк белән, кул белән
Мыш-мыш килеп маташа.
Менә кояш яктысы
Шуып та шуып барды;
Картның чаллы башына
Килде дә кунып калды.
Симек шавы урамда
Йөрәк хисен кузгата.
Әх, кояш та, уйнаклап,
Чәч бөртеген нурлата!

---

Мыгырдап та мышылдап,
Бабай сипли чабата.
Шунда кунак килгәнен
Сизми калды, тамаша!

Ачык ишек каршына
Кемдер килгән икән лә.
Ак чал чәчле бабайга
Сәлам биргән икән лә.
Картка Сәтнәр анасы
Сүзен кушкан икән лә.
Аның улын, Сәтнәрне,
Шаукым суккан икән лә.
Шуңар карчык тиз генә
Багучыга ашыккан,—
Аһ-зар орып, кайгысын
Әйтеп бирде ачыктан.
Озак алар карт белән
Сөйләштеләр калыгып;
Кайчак сүзгә җай килсә,
Үткән чакны сагынып.

---

Соңра бабай, килешеп,
Багуның хакын куйды.
Карчык бер пар оек та
Күлмәк бирергә булды.
Аннан бабай торды да,
Эшләрен ташлап читкә,
Ябып куйды ишеген,
Табагач тыкты биккә.
Тунын киде, бүреген
Тыкты култык астына.
Табан аска кыл салып,
Акча куйды алдына.
Аннан аксыл сакалын,
Көмеш чәчен тарады.
Сукырларча күз текәп,
Акчасына карады.
Багып торды-торды да
Җитен сакалын кашып;

Тезеп-тезеп сөйләде,
Карчык алдына басып:
— «Маңгай тишеге капланмас,
Йөрәк кисеге кушылмас.
Пүлех[1] тәңре язганнан
Бер бәндә дә котылмас.
Биргән аңар пүлехче
Кайнар кан да назлы җан.
Биргән аңар пүлехче
Кыска гомер, зарлы җан.
Суык көннәр килер дә,
Туңып китәр кайнар кан.
Каты көннәр килер дә,
Катып китәр йомшак җан.
Кайнар көннәр килер дә,
Кайнарланыр салкын кан.
Йомшак көннәр килер дә,
Йомшап калыр каткан җан».
Аннан бабай, тукталып,
Уйга батып торды да;
Ертык тунын, бүреген,
Читкә илтеп куйды да
Тагын сүзгә кереште,
Шулай, бераз хәл алып.
Тора карчык сәкедә,
Арлы-бирле каранып.
— «Төрле шаукым килмәгән,
Кирәмәт[2] суккан түгел.

---

[1] Пүлех, пүлехче — мәҗүсилек алласы. Сүзгә сүз тәрҗемәсе — бүләк, бүләкче.

[2] Кирәмәт — явыз, усал рух. Элек чувашлар кирәмәт дигән ямьсез, карт, «изге» агачка табынганнар, аның явызлык кылуыннан куркып, аңар төрле бүләкләр, сыйлар ташып торганнар. Чуваш авыз иҗатында кирәмәт турында күп кенә легендалар саклана.

Йөрех[1] хәстә бирмәгән,
Сихерләп куйган түгел.
Юк, юк, килен, углыңа
Ходай язган шул инде.
Елый күрмә, тәңренең
Колы гына бул инде!..»
Бабай шулай сөйләде,
Ни кылырга белмәде.
Үз эшләрен көйләде,
Башка сүзгә кермәде.
Карчык чыкты, кайгыдан
Башын түбәнгә салды.
Чабатасын кармалап,
Бабай утырып калды.
Мыгырдап та мышылдап,
Аптырый ул, үкенә.
«Нигә болай бу бүген?»—
Сорау бирә үзенә.
«Хәзергәчәк халыкка
Багулар бага идем,
Юк-бар әйтеп, алдалап,
Озатып кала идем.
Нигә болай бу бүген?
Әллә монысы рас микән?
Алдалармын дидем дә,
Ах тамаша! Хак микән?»

---

[1] Йөрех — явыз, усал рух. Мәҗүсилектән калган

## 6. КАЧУ

Кояш бата, кич керә,
Силби авылы тын кала.
Караңгылык төшкәндә,
Безнең туй да туктала.
Матур кызлар, егетләр
Уенга чыкты тагын.
Чыкты безнең Нарспи да
Озатырга кыз чагын.
Соңгы тапкыр уйнарга —
Хатын булып җиткәнче;
Күрим диеп Сәтнәрне
Җиде ятка киткәнче.
Сәтнәр тора тын гына,
Башын игән кайгырып.
Чибәр кызның күзеннән
Яшьләр чыга саркылып.
Уен беткәч, серләшеп,
Алар җаен таптылар:
Кара төндә, бер-берен
Кочаклашып, качтылар.

---

Вак йолдызлар еракта
Балкып янмый башлады.

Урман өстен кап-кара
Шомлы болыт каплады.
Яңгыр ява, су гөрли,
Дөм урманны селкетә.
Ач бүре күк улап гел,
Җил чыга да җил китә.
Яшен уйный, ялтырый,
Шаулы урман яктыра.
Кара урман эченнән
Бер ат алга ашкына.
Бара ул ат, урманны
Яңгыратып пошкыра.
Икәү булгач өстендә,
Арый тәмам, йончыла.
Агач тора Алып[1] күк
Караңгыда шау килеп.
«Хәерле юл!» дигән күк
Башын бөгә җай биреп.

---

Таң алдында яп-якты,
Кояш чыгар чибәр чак.
Таң алдында — ак офык,
Туйга вакыт җитәр чак.
Егетләргә биешергә
Вакыт җитәр яхшы чак,
Кызларына җырларга
Вакыт җитәр якты чак.
Шыбыр моңы ишетелми,
Уйнаучысы күренми.
Кунак-төшем алдында
Сыра-фәлән түгелми.

---

[1] Алып — чувашларда, шулай ук татарларда мифик герой, гигант кеше.

Карчык белән Михәдәр
Кара өйдә талаша.
Ни булды соң бу болай?
Бар да тыныч лабаса!
Тыныч тормый! Кыз юк ич!
Шул чыкмасын уеңнан!
Сәтнәр — Нарспи икәүләп
Качкан кичә уеннан!

---

Урманда өч атлы бар,
Нәрсә эшлиләр алар?
Бер анда да бер монда,
Кемне эзлиләр алар?
Эзлиләр дә тыңлыйлар:
Берәр тавыш килмәсме?
Кояш чыга яктырып,
Кирәк юлны бирмәсме?
Ләкин һичкем күренми,
Эчтәнрәкме карарга?
Шунда кемдер мыгырдый:
— Ничек тизрәк табарга?
Кара урман, дөм урман
Гөжләп тора давылда.
Юк кына бит җирдә эз,
Инде каян барырга?
Урманда өч атлы бар,
Нәрсә эшлиләр алар?
Бер анда да бер монда,
Кемне эзлиләр алар?

---

Сәтнәр йоклый үлгән күк,
Биек имән шыгында.
Нарспи калгып утыра
Сөйгәненең кырында.

Менә Нарспи төш күрә;
Әтисе эт булган да
Шакырдатып тешләрен
Чабып йөри урманда.
— «Кая качтың, явыз кыз?
Ашыйм!» диеп ырылдый.
Шул эт аяк астында
Кара урман шыгырдый.
Җитә, җитә! Аһ, җитте! —
Нарспи кинәт сискәнде.
Күрде шунда өч атта
Ятлар килеп җиткәнне.
— Сәтнәр, Сәтнәр, тоттылар!
Тор, тор, качып котылыйк!
Ай беттек лә, ай беттек!
Кайда китик, ни кылыйк?

---

Бүген матур шыбырчы,
Юлдаш итеп яшьләрне
Тотып килде урманнан
Нарспи белән Сәтнәрне.
Карчык җилеп чыкты да
Кунды Нарспи чәченә,
Карты чабып чыкты да
Сукты Сәтнәр башына.
— Әй әнкәем, әнкәем,
Чәчем болай йолыкма!
Мине шулай өйрәтсәң,
Хәере булмас, онытма!
— Әй Михәдәр, бабакай,
Кыйнавыңнан ни файда?
Көлдән мәңге ут булмас,
Усаллыгың ит әйдә! —
Бу сүздән соң Михәдәр
Тагын эттәй котырды.

Бәйләп куйган Сәтнәрне
Камчыларга тотынды.
Йортта халык бик тә күп,
Туй күрергә килгән күк.
Сәтнәр ята туфракта
Күптән җанын биргән күк.
Әнкәсе дә шушында,
Тора әрнеп, яшь сыгып.
Җибәрә ул баласын,
Күршеләргә тапшырып.
Ата-ана Нарспиның
Битен-күзен юдырта;
Тагын чаршау артына —
Бөркәнчеккә утырта.
Тыпыр-тыпыр тыпырдат!
Әйдә, туйлар гөрләсен!
Ләкин бу хәл турында
Яңа кияү [1] белмәсен!

Әнә туй да менә туй!
Кызык туй да бозык туй!

---

[1] Яңа кияү. Шагыйрь биредә, «яңа кияү» дип, Тохтаманнан көлә. Чөнки аңа чаклы инде Нарспи белән Сәтнәр урманда төн үткәрәләр.

## 7. ИКЕ ТУЙ

Байый язгы ут-кояш,
Соңгы кабат ялтырап.
Ерак түгел дөм урман
Тора никтер яңгырап.
Халык көтә бик озак
Кыр капкасы каршында.
Кода кинәт, «килә!» дип,
Шатландыра барсын да.
Шау-гөр килеп, урманнан
Атлар чыкты бер заман.
Барысыннан алдарак —
Яңа кияү Тохтаман.
Ялпак борын, кысык күз,
Сакал — сары, чәч — сары.
Атлар очып барса да,
Җимерелгән кашлары.
Кара чикмән, шәп бүрек,
Маңгаенда тәңкәсе.
Ак тула да чабата —
Әй килешә гәүдәсе!

—

Кияү туе, җырлашып,
Урам буйлап агыла.

Башкоданың капкасы
Ачыла да ябыла.
Кыз туе да Тугастан
Килеп чыга каршыга.
Нарспи яулык астында
Үкси-үкси яшь сыга.
Ярсый кызның йөрәге,
Дөрләп утта яна ул.
Карт киявен күрә дә
Кайгы чигә янә ул.
— Әй әткәем, әнкәем!
Хур иттегез нигә сез?
Ник җиде ят кулына
Кызыгызны бирәсез?
Әй киявем Тохтаман!
Юкка өмет сузасың!
Башым бетсен, юк ләкин
Синең белән буласым!

---

Кода, сыра күтәреп,
Туйга каршы йөгерә.
Хушылкалы кияүгә
Такмак әйтеп өлгерә.
Кода чаба, түгелә
Кулындагы бал-сыра.
Кара аткай тик тормый,
Яңа кияү чаптыра.
Җиде кияү егете —
Ат өстендә барысы.
Дер күтәрә авылны
Җыр да бию тавышы.
Яңа, матур капкадан
Арба кереп барганда,
Капка башы шакылдый,
Камчы тиеп калганда.

Юмарт кода өендә,
Туйда рәхәт сөрделәр.
Иртәгесен авылда
Кунак булып йөрделәр.

---

Өч көн туйны иттеләр
Хушылкалы кодалар.
Ләкин инде кайтырга
Вакыт диеп торалар.
Кияү туе җыйнала,—
Хушылкага өйдә,— ди.—
Монда туйны уздырдык,
Инде ясыйк өйдә,— ди.
— Ашыкмагыз, кодалар,
Башка өйгә барыйкчы!
Китмәс борын, бу туйны
Шәбрәк ясап калыйкчы!—
Тагын-тагын бер тоташ
Туйны дәвам иттеләр.
Алҗып бетте кодалар,
Туйны тәмам иттеләр.
Кияү туе кузгалды,—
Җитәр, артык сыйланды!
Киткән туйны озатырга
Бөтен Силби җыйналды.

---

Олы зиарат янында
Туй атлары торалар.
Ата-ана да шунда ук,
Кызны озата баралар.
Туй янында кешеләр
Шау-гөр килеп торалар.
Әрвахларны хәтерләп,
Кызны озата баралар.

Авыру Сәтнәр шушында
Тора анасы белән.
Әзли сөйгән Нарспиен
Моңсу карашы белән.
Михәдәр дә, карчык та
Кызны бәхил кылдылар.
Кардәш-дусны елатып,
Яшь агызган булдылар.
Сөйгән кызга бер сүз дә
Әйтмәделәр үзләре,—
Сәтнәр белән, имештер,
Качкан өчен үчләре!

---

Бәхилләшкәч, эш беткәч,
Туй да китте ашкынып.
Сәтнәр йөзен күргәч тә
Нарспи елый ярсынып.
Урман торды яңгырап,
Туй шушында юл алгач.
Бар да өйгә атлады,
Атлар күздән югалгач.
Сәтнәр китте кайгырып
Газиз анасы белән.
Калды шулай кавышмый
Йөрәк пәрасы белән.
— Әй бу тормыш, бу тормыш!
Ләкин үлем җитте шул!
Әй бу тормыш! Нарспи да
Җиде ятка китте шул!
Аннан башка ни кылыйм?
Ник мин болай бичара?
Кайда барып керим соң,
Кайгы-зардан ни чара?
Нарспи китте ят җиргә,
Сәтнәр өенә атлады.

Ике җан да — гашыйк җан
Байны җиңә алмады.
Гашыйкларның качканын
Урман каплап тормаган.
Матур кызны, Нарспины,
Алды, алды Тохтаман!
Калдырдылар бер ялгыз
Сәтнәр — гашыйк баланы.
Бәлки, ходай язгандыр,
Шулай ахры заманны...
Бик күп аның турында
Фәлән-төгән сөйлиләр.
Тик акыллы ирләр дә
Рәтен-чабын белмиләр.
Нарспи китте, Сәтнәре
Ялгыз чигә бу гамен.
Атасы ашый кыз башын,
Туган ашый туганын.

## 8. ХУШЫЛКАДА

Хушылкада туй икән,
Туе бигрәк мул икән.
Чал сакаллы Тохтаман —
Туй итүче — шул икән.
Чибәр егет Тохтаман
Силби кызын хур итә.
Бүген шундый тиңнәргә
Дөбер-шатыр туй итә.
Матур кияү егетләр,
Бетә биеп көчләре.
Туй җырларын гөрләтеп,
Чатный тамак төпләре.
Кичә Силби авылыннан
Кайтты туен үткәреп.
Кияү көтә кыз туен,
Туй шау-шуы күтәреп.
Уйлый, бүген туй килсә,
Кызны кертеп ябарга;
Иртә торган вакытка
Кыздан хатын ясарга.

---

Бик зур авыл Хушылка,
Тау һәр ике ягында.
Туй итеп гел Тохтаман
Утыра өстәл янында.

Төрле ашлар астында
Юкә өстәл сыгыла.
Исерек кияү башында
Дөнья выр-выр борыла.
Тышта кояш нур чәчә,
Менә төшлек тавына.
Кияү башы, исергәч,
Түбән таба салына.
Аулак кырда бүдәнә
Вакыт-вакыт җыр суза.
Туй килмиме әле?— дип,—
Аптырата гел хуҗа.
Акбүз күлмәк кияүдә,
Кисәк дер-дер селкенә.
Туйны көтеп, картлачта
Йөрәк дер-дер селкенә.

---

Чыңгыр-чыңгыр кыңгырау,
Атлар чаба юллардан,
Җир җимертеп, кыз туе
Килеп чыкты урманнан.
Хушбу [1] кигән ун хатын
Күн күмәнең алдында.
Кырык өч ат тезелгән
Күн күмәнең артында.
Җиде җирдә — җиде сый,
Кайда җитте — шушында.
Сыра белән каршылый
Килен туен Хушылка.
Җырлыйлар да керәләр,
Кияү капка ачкачтын.

---

[1] Хушбу — көмеш тәңкәләр белән бизәлгән хатын-кыз баш киеме. Аны туй вакытында гына кигәннәр.

Ашыйлар да эчәләр,
Ерак юллар ашкачтын.
Күрче, төш тә җитмәгән,
Кичкә вакыт күп әле!
Төнгә чаклы туй ясыйк,
Бик тә вакыт күп әле!

---

Ашап-эчеп, биешеп,
Көч алгач та йөрәккә —
Тохтаманны, Нарспины
Бикләделәр келәткә.
Зирәк ирләр ишеккә
Таза йозак тактылар.
Аннан, пых-пых көлешеп,
Өйгә таба чаптылар.
Менә егет, бер егет,
Келәт буен сагалый.
Тыңларга да карарга
Аулак урын чамалый.
Дүрт-биш бала маташа
Колак салып карарга.
— Әй оятсыз малайлар,
Ни эшегез бар анда?
Ләкин алар тыңлыйлар.
— Тавыш бар күк, кил менә!
Тынып калды малайлар.
— Чү, кыз сөйли, тик кенә!
Эчтә Нарспи нәрсәдер
Сөйләгәндә туктады.
Ләкин тавыш бик акрын,
Берни ишетеп булмады.
— Бел син, Нарспи, моннан соң
Минем кулда йөгәнең! —
Диде шунда Тохтаман,
Баса алмый йөрәген.

Туйны кире озатыйм,
Аннан мине белерсең!
Ни буласын кем әйтер?
Ни күрәсен күрерсең!
Башка берни ишетелми,
Бер тавыш та килмәде;
Тыштагылар көтсә дә,
Бүтән бер өн сизмәде.
Шундук бала-чагалар
Өйгә чабып китәләр;
Ишетелгән сүзләрне
Түкми-чәчми илтәләр.
Тыңлап торган шул егет
Урманлыкка атлады.
Ишетеп алган сүзләрне
Күңеленнән ятлады.
Аның усал күзләрен
Ялтыр утлар сардылар.
Кергән-чыккан кунаклар
Белми-күрми калдылар.
Имән ләкин урманда
Бик тиз таный яшьләрне:
Күрде үзенең янында
Безнең туган Сәтнәрне.

---

Ботка — өстәл өстендә,
Өйгә булар күтәрә.
Яңа кияү Тохтаман
Соң кат кунак үткәрә.
Юмарт кияү Тохтаман
Туй ботгасы ашата.
Туй халкына баш орып,
Шулай сөйләп озата:
— Үпкәләшмик, кодалар,
Сый күп түгел табында.

Ашыйк-эчик, бергәләп
Гомер итик тагын да!
Топма исрек кунаклар
Гөбер-гөбер гөрлиләр.
Топма исрек баштан да
Барын белеп сөйлиләр:
— Әй кияүкәй Тохтаман!
Юк үпкәләр җирегез!
Безнең кызны каты тот,
Тату гомер сөрегез!
Тышта атлар торалар,
Биеп-дулап, җилкенеп.
Чыгып китте кодалар,
Җырны юмарт сиптереп:
— Әйдә киттек мал белән,
Чүлмәк тулы бал белән...»
Арбаларның артыннан
Тузан купты шау белән.
Матур яңрый кыңгырау,
Юл туп-туры Силбигә.
Атлар чаба баш иеп,
Исрекләрдә — дилбегә.
Туй бетте дә туй китә,
Такыр юлдан сыптыра.
Берәр карты очраса,
Сәлам!— диеп кычкыра.
Киткән туйның тавышын
Нарспи калды ишетеп.
Әллә кайда еракта
Тузан калды ишелеп...

0462.

## 9. СИМЕК ҮТКӘЧ

Үтте симек, үтте туй,
Үтте туйның рәхәте.
Узды, бер-бер тезелеп,
Сәгать арты сәгате.
Кырда, сабан астында,
Чирәм чырт-чырт киселә.
Зәһәр кайгы-сагыштан
Нарспи җаны өзелә.
Кырда, чалгы астында,
Печән вышт-вышт егыла.
Зәһәр кайгы-сагыштан
Нарспи башы бөгелә.
Кояш нурлый көннән-көн
Җирнең бөтен төбәген.
Кайгы-сагыш көннән-көн
Ашый Нарспи йөрәген.
Көн дә, көн дә саламат [1]
Төшә тора колгадан,—
Каты тота шулкадәр
Үз хатынын Тохтаман.

---

[1] Саламат — каеш камчы яки чыбыркы.

Чибәр бала Сәнтти бар,—
Чабып йөри урамда.
Көянтәгә атланып,
Ат-ат уйный ул анда.
Ул зур урам буйлата
Чиксез тузан кубара.
Кара чегән күк кара
Кайта кичен бу бала.
Чибәр бала Сәнтти бар,—
Чабып килә, атланып.
Сөйли нәни тел белән,
Җиңгәсенә якланып.
Нарспи-килен яңа шул,
Гел кайгыра, көя ул.
Биаганың баласын —
Тик Сәнттине сөя ул.
Нарспи-килен яңа шул,
Гел сагышлый, яна ул.
Сәнтти белән сөйләшеп,
Җан тынгысы ала ул.
Шундый яхшы баланы
Тәңре шулай кыла шул;
Уйный, көлә, — аңарда
Аккош җаны тора шул.
Җиде яшьлек балага
Чуваш җаны керә шул;
Нәни күзе еласа —
Нәфис ирене көлә шул.
Чибәр бала Сәнтти бар,—
Кайчан гына килмәсен —
Татлы нәни тел белән
Юата һаман җиңгәсен:
— Менә яулык. Яшьләрең
Җиргә түкмә, җиңгәем.

Куып җибәр кайгыңны,
Кайгы чикмә, җиңгәем!

---

Туй келәтен Тохтаман
Истә тота галәмәт!
Көн дә, көн дә хатынга
Төшеп тора саламат.
Мескен хатын чыдый шул,
Белми һич тә чарасын.
Ахмак кияү белми тик
Эшнең кайда барасын.
Бер көнне килде берәү,
Кияү белән сөйләште.
Нарспи юкта, икесе тик
Пыш-пыш нидер серләште.
Нарспи керде кунакны
Сыра белән сыйларга.
Кунак китте, Тохтаман
Тагын килде кыйнарга.
— Һә, син шундый кыз икән!
Көлкегә калдыңмыни?
Сәтнәр белән, туй көнне
Урманга качтыңмыни?
Кыйный, кыйный Тохтаман,
Төрле газап чиктерә.
Хәзер халык теленнән
Төрле сүзләр ишетелә.
Алай-болай — шулай шул,
Андый эш күп як-якта.
Начар нәрсә күп була
Ышык төштә, аулакта...
Ата-анасы үз кызын
Сөйсә һаман, көйләсә —
Әмма хатын булгачтын,
Гел карт ире көнләшә.

Ата-анасы үз кызын
Тотты бирде бер байга.
Яратмагач бер-берен,
Юк тик аннан бер файда!
Икәү тату көн итсәң,
Барып гыйшык җаеннан,—
Йөз тапкыр бәхетлерәк
Ярлы кеше — баеңнан!
Кыйна, кыйна, Тохтаман!
Җанын чыгар, җәлләмә!
Газапландыр, Тохтаман,
Эт ит, бетер, бәргәлә!
Кыйна, кыйна, Тохтаман!
Яшьләр шулай җайлансын!
Газапландыр, Тохтаман,
Нарспи тизрәк чаллансын!
Ләкин сиңа соңыннан
Үкенеч-фәлән килмәсен,—
Кыйна, кыйна, Тохтаман,
Яшьләр синнән көлмәсен!
Үтеп китте өч атна,—
Туй да симек артыннан.
Ирдән күргән золымга
Нарспи түзде. Ахрыннан...
Ләкин бүтән атнада,
Айлы, матур бер кичтә...
Тик, чү, әлегә сөйләмим,
Калып торсын бер читтә!

## 10. НАРСПИ ӘШЕ

Кояш иртән тау менеп,
Күккә башын калкыта.
Җылы, юмарт нур белән
Дөнья йөзен балкыта.
Җәйге көндә Хушылка
Якты нурга каплана.
Бар дөньяда тере җан
Биеп тора, шатлана.
Җибәрделәр җыр сузып
Дөм-дөм урман кошлары,
Аккошлардай тезелеп,
Суга төште кызлары.
Ләкин менә ак йортта
Бер тын да юк, шомлы чак.
Килен кеше ак йортта,—
Бер ялгыз ул. Моңлы чак.
Иртән, терлек ашаткач,
Китте кырга Тохтаман.
Бүген мескен хатынын
Тагын кайгы чолгаган.
— Хатын булдым ирексез,—
Әткәй, әнкәй — нәфесле.
Ләкин мескен кызыгыз
Булдымы соң бәхетле?

Кызганмыйча, мал итеп,
Җиде ятка саттыгыз.
Мин — кызыгыз, мескенне
Янган утка аттыгыз!
Хәзер мескен кызыгыз,
Газап чигеп, сүнә бит.
Каһәр төшкән карт аны
Эттән түбән күрә бит!
Ник соң мине сез шулай
Аердыгыз ярымнан?
Ник соң монда килгәнче
Аерылмадым җанымнан?
Явыз белән бер өйдә
Ничек бергә торыйм соң?
Әллә башым бетеримме?
Ничек кенә чыдыйм соң?
— Көчләп иргә бирделәр,
Газап-моңга салдылар.
Әткәй-әнкәй аңсызлар,—
Миндә фәкать кайгы-зар.
Көчләп иргә бирделәр,—
Рәхәт түгел көннәрем.
Әткәй-әнкәй аңсызлар,—
Калды минем сөйгәнем.
Көчләп иргә бирделәр,—
Исмем черде, чүп булды.
Әткәй-әнкәй аңсызлар,—
Кайгы-газап күп булды.
Көчләп иргә бирделәр,—
Минем гомер коллыкта.
Әткәй-әнкәй аңсызлар,—
Нинди мәгънә тормышта?
Көчләп иргә бирделәр,—
Газап-моңга салдылар.

Әткәй-әнкәй аңсызлар,—
Миндә фәкать кайгы-зар...
— Ләкин минем иркәм бар,
Ирек китерер микән?
Көчле кулы дошманны
Изеп бетерер микән?
Юк, үз башым беткәнче,
Дошманымны юк итәм;
Газап күреп түзгәнче,
Тохтаманны... юк итәм!
Ләкин көчем җитәрме?
Ни хәл итим, пүлехче!
Качып китеп булырмы?
Җаным тетри, булышчы!
Бетсәм бетим, бет, дошман!
Минем тормыш зар-сагыш.
Белгән эшең эшләп бир
Бүген әйдә, наргымыш[1]!
Нарспи, мескен, сукрана,
Кайгы чигә, хурлана.
Җаны тетри, башында
Усал уйлар кузгала...

---

Ут күк кояш, уйнаклап,
Үрли бара түбәгә.
Акрын-акрын төш җитә,
Кыска кала күләгә.
Тышта дөнья җемелди,
Тышта дөнья сөенә.
Нарспи елый бүлмәдә,
Газап чигә, көенә.
Сәнтти кайта атланып,
Көянтәсен сикертеп.

[1] Наргымыш — үтергеч агу, мышьяк.

Җиңги!— диеп, шау килеп,
Керец китте җимертеп.
Кыйный батыр атчыгын,
Чыбык белән шап та шып.
Белми-күрми, җиңгәсен
Китә язды таптатып.
Ләкин ул да җиңгәсен
Бүген аңлый алмады;
Атын алып, аптырап,
Өйдән тышка атлады.

---

Салма бутый яшь килен,
Өрә, төкерә, пышылдый.
Учак яна, елан күк
Боргалана, чыжылдый.
«Җитмеш диңгез ягыннан
Килче, карчык Шаппатан[1]!
Өр дә төкер салмага,—
Бетсен усал Тохтаман!
Алтмыш диңгез артында
Уйный, сикерә җиз бүкән.
Сикер, сикер катырак,—
Китсен усал йөзтүбән!
Утыз да бер тауларда
Салма пешер, җиз казан!
Шул салмада пеш, елан!
Тамугка төш, Тохтаман!»
Салма бутый яшь килен,
Өрә, төкерә, пышылдый.
Үлем ашы елан күк
Сыргалана, чыжылдый...

---

[1] Шаппатан, Шабадан карчык — ырымнар вакытында телгә алына торган мифик җан иясе. Мәҗүсиләр ышануынча ул коточкыч ямьсез була, авызында бары тик бер алгы теше генә бар.

Кайта кичен Тохтаман,
Керә атын тугарып.
Салма өстәл өстендә
Тора булар чыгарып.
Кашык алып, Тохтаман
Керде өстәл артына.
— Салма бүген тәмле! — дип,
Мактап куйды аз гына.
Ямьсез күзен боргалап,
Йодрык кысып җилкенә:
— Салма тәмле, кил монда!
Кил, дим, утыр тиз генә!
— Юк, юк, килми ашыйсым,
Өлгерермен соңыннан!..
Аһ, Нарспи да, түзмичә,
Китте өстәл кырыннан...
Тышта тора яшь хатын,
Яшен җиргә агызып.
Карты ашый, салмага
Әфен-төфен ябышып...

---

Тыгын, тыгын, Тохтаман,
Наргымышлы салманы!
Хәзер синең Нарспига
Ирлек көнең калмады!
Беттең инде, Тохтаман,
Дөньяң сүнде, күшәп кал!
— Нарспи, тизрәк өйгә кер,
Йокым килә, түшәк сал!
«Менә ходай, нишләдем?
Эчтә тамуг тора кук.
Күбенгәнче, туйганчы
Су да эчтем — сыра кук...»
Нарспи керде, күренми

Тохтамаңга ак-кара:
Бөтен эчен-бавырын
Зәһәр салма актара.
Нарспи урын җәйде дә
Илтеп ирен яткырды.
Тотып-тотып бәрде дә
Җанын күккә аштырды.
Бетте бер җан дөньяда,
Вәхшилеккә чик җитте.
Бетте ерткыч гомергә,
Йөрәк тынды, тир кипте.
Өйдә өстәл, бүкәннәр
Хәтәр булып сизелде;
Күреп хуҗа гәүдәсен,
Кызганалар шикелле.
Менә иркен җир йөзен
Караңгылык каплады.
Төнге тынлык Нарспины
Куркындыра башлады.
Бетте карты гомергә,
Инде торып йөрмәс ул.
Ач ат, сыер, сарыкка,
Чыгып азык бирмәс ул.
Менә атлар ачлыктан
Кешнәшәләр абзарда.
Ләкин сезне, үксезләр,
Хуҗа юк шул аңларга!

---

Авыл чите — дөм урман,
Яфрак, ботак дерелди.
Мең-мең йолдыз, уйнаклап,
Иркен күктә җемелди.
Хушылкада чувашлар
Йоклый бар да хырылдап.

Очты тик бер ябалак
Бакча буйлап, пырылдап.
Айның сырты, тәгәрәп,
Чыкты урман сыртыннан.
Атлый-атлый тын гына,
Чыкты Нарспи йортыннан.
Барды шәүлә күк шуып,
Бакча артлап узганда.
Китте чыгып авылдан,
Чабып керде урманга.
Бер күрим, дип, омтылып,
Ай да чапты җемелдәп.
Ләкин урман калды күк,
Нарспи узгач, гөжелдәп.

---

Нарспи бара урманнан,
Ялт-йолт итә шәүләсе.
Нарспи җанын куркытып,
Тып-тын тора һәммәсе.
Кәкре-бөкре агачлар
Җиргә иелеп калалар,
Нарспи чабып үткәндә,
Киң юл бирә баралар.
Карт агачлар төбендә
Шүрәлеләр[1] уйныйлар;
Нарспи чабып узганда,
Кул сузарга уйлыйлар.
Кисәк җилдән дөм урман
Гүләп куйды бер заман;
Улый күк ул бар яктан:
— «Тот хатының, Тохтаман!
Тот хатының, Тохтаман!

---

[1] Шүрәле чуваш мифологиясендә дә бар. Чуваштa ул „арҗури“ дип атала.

Качып китте, ух явыз!»
Утыз да бер шайтандай
Урман ыжлый: «ыж» да «ыж»!

---

Иртән торып киенгәч,
Сәнтти чыкты йөрергә.
Ат-ат уйнап килде ул
Дус җиңгәсен күрергә.
Ләкин җиңгә күренми,
Йоклый һаман абзыйсы.
Сәнтти тора аптырап,—
Әллә селкеп карыйсы?
Берәү килеп керде дә,
Катып китте, онтылып.
Карап торды-торды да,
Чабып чыкты омтылып.
Халык тулды. Мондый хәл
Таң калдыра барчасын.
— Ничек үлгән Тохтаман?
Нарспи килен кайда соң?
Юк шул, күпме сорап та
Мәет әйтмәс, өне юк!
Нарспи йөри урманда,—
Табыйм димә, эзе юк!

## 11. СИЛБИДӘ

Олы Силби авылында
Тормыш бара һаман да.
Үтте симек шатлыгы,
Узып тора заман да.
Чуар — чуваш күлмәге.
Чуар — болын өсләре.
Чуваш эшли үгез күк,—
Җырлап тора эшләре.
Таң атканчы тора ул,
Киң болынга бара ул.
Ялт-йолт кабып ала да
Иңгә чалгы сала ул.
Учүк[1] үткәч чувашлар
Барсы авыл кырында.
Чүмәләләр, кибәннәр
Торып кала болында.
Үткен чалгы чыжылдый,
Соңгы чалу читендә.

---

[1] Учүк — корбан чалу бәйрәме. Элек чувашлар, йорт саен акча җыеп, ат яки бүтән терлек сатып алганнар да аны, симек атнасында, бөтен авыл белән бергәләп суеп, урман аланында пешереп ашаганнар, бергә гыйбадәт кылып, игеннәрнең бәрәкәтле уңуын теләгәннәр.

Башлы арыш саргая
Иркен басу битендә.

---

Төрле сүз күп авылда,
Сөяксез тел очында.
Дөресләр дә бардыр шул
Юк-бар хәбәр эчендә.
Силбидә дә адәмнәр
Нарспи, Тохтаман, диләр.
Алар, күптән кияүнең
Усаллыгы бар, диләр.
Михәдәрдән шикләнеп,
Сүзләр йөри сак кына.
Аптыраган чувашлар
Кашып куя баш кына.
Сәтнәр — егет, ишеткәч
Моны бик күп авыздан,
Әнкәсенә сүз әйтми,
Чыгып китте авылдан.
Кырда да гел кешеләр
Гашыйкларны җәллиләр.
Кичке аш-су алдында
Нарспи да Сәтнәр, диләр.

---

Сәтнәр атлый урманнан,
Бигрәк авыр вөҗданга.
Уйлап Нарспи газабын,
Янап бара дошманга:
— Шәфәкъ батар, кич булыр
Хушылкага җиткәнче;
Тынар дошман йөрәге
Кояш нурын сипкәнче!
Кояш чыгар, яктыртыр,
Халык торыр авылда.

Ләкин дошман уянмас,
Йокы артык авырга!
Кояш чыгар, яктырыр,
Мин ул чакны — урманда!
Ләкин дошман кузгалмас,
Нарспи булмас урында!
Әмма Нарспи ансыз да
Чыкты кичен авылдан.
Сәтнәр килеп җиткәнче
Качып китте явыздан!

# 12. УРМАНДА

Шаулый, гөжли дөм урман,
Аның кырые-чиге юк.
Кул-аяксыз җил чыкты,
Мәңге туктар җире юк.
Шаулый, гөжли дөм урман,
Тамугмыни!— улый ул.
Шүрәле күк, шайтан күк
Чиный, үкерә, елый ул...
Кабат-кабат җил килә,
Выж-выж дулап, тыгылып.
Кара урман гөрелди,
Җиргә кадәр сыгылып.
Кара болыт өзлексез
Килә урман артыннан.
Яшен бәрә, җир ярып,
Кара болыт астыннан.
Яшен бәрә, шартлата,
Бөтен дөнья дер килә.
Чиләк-чиләк яңгырдан
Чокыр-чакыр гөр килә.

---

— Дөм-дөм урман, дөм урман,
Ник соң болай шаулыйсың?

Ник соң, выж-выж сызгырып,
Мескен җаным даулыйсың?
Урман тагын катырак
Шаулый, елый, тулгана.
Тәңрем, кичер, ташлама!
Ахыр заман кузгала!
Аһ, гөнаһлы башымны
Кайда илтеп салыйм соң?
Аһ, гөнаһлы җанымны
Ничек йолып калыйм соң?
Бүген Сәтнәр, мескенем,
Азгын, шашкын урманда.
Ыжлый калын наратлар,
Гөрләп давыл узганда.
Егет — кысан сукмакта,
Җырлый йөрәк сагышын.
Сәтнәр бара. Җырлары
Каплый урман тавышын:
— Дөм-дөм урман, дөм урман,
Ник соң болай шаулыйсың?
Ник соң, выж-выж сызгырып,
Мескен җаным даулыйсың?
Аһ син, кайгым, тыңлачы,
Нигә ут күк кабасың?
Ник соң миңа, үксезгә,
Өметсезлек саласың?
Тудым газиз әнкәмнән,
Мине хәсрәт көтте тик.
Авыр, ким-хур, газапта
Башым гына бетте тик.
Башым бетмәс иде дә —
Малым юклык — шул изде.
Анысы узар иде дә —
Ахмак җаннар хур итте.
Ахмак җаннар бер бәла,

Усал дошман тап булды.
Усал дошман чүп кенә,
Хода язган хак булды!..

---

Сәтнәр җырлый җырларын,
Давыл җирне селкетә.
Сәтнәр моңын гөрләтеп,
Елап, шаулап җил китә.
Шул кайгылы тавышлар,
Елап, җанны кисәләр,
Агып көчле җил белән,
Ерак-ерак китәләр...
Алар урман эчендә
Акрын-акрын сеңәләр;
Шушы яшьле авазлар
Бер яшь җанга керәләр.
Ерактарак, кайдадыр,
Берәү тагын кан елый.
Усал газап-кайгыдан
Анда башка җан елый.
Серле җырның моңнарын
Сәтнәр тыңлый ашкынып.
Көчле җилдә, давылда
Сәтнәр җырлый ярсынып:
— Кара урман, дөм урман,
Ник син мине юаттың?
Иркәм булып җыр сузып,
Үлгән җаным уяттың?
Тыгыз урман, дөм урман,
Зинһар алдап җырлама!
Иркәм булып җыр сузып,
Газап-моңга чолгама!
Калын урман, дөм урман,
Әйтче чынын, килсәнә!

Мескен җаным кызганып,
Җан сөйгәнем бирсәнә!
Тукта, килә хатын-кыз!
Әллә минем тиңме бу?
Олуг турым, ярлыка! —
Нарспи, Нарспи! Синме бу?

---

Ике гашыйк кавышкач,
Баш иделәр агачлар.
Урман тынды, җил бетте,
Бетте шомлы авазлар.
Җилләр урман артына
Болытларны каулады.
Кояш сипте нурларын,
Асыл кошлар сайрады.
Чирәмдәге чыкларга
Кояш бирә яктысын.
Ике яшь җан — гашыйкка
Кояш бирә ялкынын.
Балкый матур, яңа көн, —
Усал көннең эзе юк!
Сөешеп атлый ике җан, —
Җиде ятның эше юк!
Шунда ләкин каракош
Чинап куйды бер заман:
Нарспи җанын эзли гел,
Ай, Тохтаман, Тохтаман!

## 13. АТА-АНА

Кеп-кечкенә бер өйдә
Икәү алар, килде аш.
Тәп-тәбәнәк өстәлдә
Ашый алар кичке аш.
Читтән Сәтнәр әнкәсе
Катык тапты аз гына.
Икмәк-тозын чыгарып
Куйды алар алдына.
Ризыклана ике җан,—
Җылы сүзләр — табында.
Тып-тын Сәтнәр әнкәсе,
Тыңлап тора барын да.
Сагыналар үткәнне,—
Матур, тыныч көннәрне,
Кичке әйлән-бәйләнне,
Симеккәчә төннәрне...
Кинәт кенә куркытып,
Китте ишек ачылып.
Михәдәр дә, карчык та
Килде керде ашыгып.

Карчык

Безнең Нарспи бу йортта
Юк микән, дип кердек без.

Яхшы дуслар сүзеннән
Монда диеп белдек без.

Михәдәр

Әх кыз, кы-ыз, кызмы син?
Нарспи, кайда башларың?
Нигә халык каршында
Хурлыкларга ташладың?
Ни җитмәгән соң сиңа?
Яман атың чыгардың?
Ник берннгә карамый
Сәтнәр-эткә сыландың?
Бай кыз булган башыңнан
Ник соң болай тилердең?
Мәңге хурлык күрмәдем,
Инде хәзер китердең!

Карчык

Ни җитмәгән әхмакка
Ирен үтереп качарга?
Сәтнәр белән урманда
Лаштыр-лаштыр чабарга?

Михәдәр

Шөкер, шөкер ходайга!
Начар исмем булмады.
Хәзергәчәк кирәмәт
Миңа кул да сузмады.
Минем йортым-җиремә
Бакты изге фәрештә.
Шуңа исмем мактаулы,
Уңып киләм һәр эштә.
Пүлех, Корбан [1], Нур-дөнья

---

[1] Корбан. Югарыдагы искәрмәне кара. Бәрәкәтле уңыш алласы булса кирәк.

Мине сыйпап килделәр.
Кывак хуппи[1], Нур-кояш
Миңа табыш бирделәр.
Мин шул көнгә җиттем дә,
Башым түбән идерден.
Матур көнем бозылды,
Астын өскә китердең!

Карчык

Орыш ныграк, тет, хуҗам,
Сәтнәр-этнең тетмәсен!
Эштә каткан кул белән
Кызга өмет итмәсен!

Михәдәр

Нәни идең — үстердем,
Кыз күңелен тыймадым.
Сөйгән кызым булганга,
Көн-төн байлык җыйнадым.
Көн-төн эшләп, җан аттым,
Өйдә йоклап ятмадым.
Кызым өчен тырышып,
Керфекләрем япмадым.
Ничек бирим иргә, дип,
Уйлый-уйлый эшләдем.
Сөйгән кызым бәхетенә
Баерак кияү эзләдем.
Кияү таптым, туй иттем,
Менә бүген ни китте!
Минем газиз башкайга
Менә бүген ни җитте!

---

[1] Кывак хуппи — күк капкасы. Күк кабыгы, күк капусы ачылу.

Карчык

Орыш, орыш, кызганма
Йөзе кара баланы!
Син кем кызы идең соң?
Кем соң сине карады?

Михәдәр

Мин нәнидән үстердем,
Йөзен күреп, сөенеп.
Шушы яшькә җиттем дә
Башым бетте көенеп.
Әткәң, әнкәң — рәхимле,
Уйла бергә чакларны!
Сәтнәр өчен койдырдың
Безнең ап-ак чәчләрне.
Сүз дә, эш тә, байлык та
Булышмады азрак та.
Шундый бай ир бар чакта,
Болай булмас ахмак та!

Нарспи

Әй әткәем, тормышмы
Сөймәс кешең янында?
Бәхет — түгел байлыкта,
Бәхет — сөйгән ярыңда!

Карчык

Ай-яй, явыз! Бик артык
Ерма инде авызыңны!
Әнкәң эчен яндырып,
Әллә үчең алдыңмы?

Михәдәр

Ай, зур хурлык китердең!
Хәзер гайбәт йөртерләр.
Кызы фәлән-төгән, дип,
Миңа бармак төртерләр.
Ләкин авыз сөйләсен,
Гайбәт җәйсен кемнәрдер, —
Исмең черек булса да,
Син минем кыз, бердәнбер.
Әйдә, кызым, бу өйдән
Ишелеп төшмәс борын.
Тагын кияү табарбыз
Исемең чермәс борын!
Әйдә, кызым, кайгырма,
Синең этиең бар әле!
Исмең черек булса да,
Этиең маллы, бай әле!

Карчык

Әйдә, көчек, кызурак!
Миңа бер дә карамый!
Сәтнәр, көчек, киез бит,
Бай кызларын чамалый!

Нарспи

Әй әткәем, әткәем,
Нигә мине борчыйсың?
Исмем черек көенчә
Нигә өйгә кыстыйсың?

Карчык

Күрче, тагын ни әйтә!
Сөйгән кызың! Ныграк бак!

Михәдәр

Карчык, җитәр, укынма,
Кызың сүзен тыңлап бак!

Нарспи

Хатын булгач, кабаттан
Өйгә кайтып китимме?
Явыз ирдән котылгач,
Тагын газап чигимме?
Юк, юк, әткәй, йортыңа
Инде аяк та басмамын!
Шушы килеш үлсәм дә,
Кияү көтеп ятмамын!
Үстердегез сез, әткәй,
Сабый чакта сөйдегез.
Ләкин буйга җиткәч тә,
Җаным белми йөрдегез.
Мин бит сезгә баш ордым,
Мин бит сезгә табындым.
Чиккә җитә башлагач,
Җиргә ятып ялындым...
Үстердегез сез, әткәй,
Үстердегез, бактыгыз.
Ләкин үскәч, мал итеп,
Акча өчен саттыгыз!
Сабый чакта сез миңа
«Бәбкәм» дигән булдыгыз.
Нәрсә сорый кызыгыз —
Шуның барын куйдыгыз.
Үскәч, башта «тик бер ел
Көтик» дидем, көйләдем.
Әткәй оршып бетерде,
Син дә чәчтән сөйрәдең!
Ник соң минем күңелгә

Соңгы кабат кермәдең?
Әткәй, әткәй, без болай
Булмый идек, белмәдең!
Әткәй, сөйгән кызыңны
Ник бирдең соң бүрегә?
Акча гына сиңа шул
Рәхәт булып күренә!
Шундый авыр хурлыкка
Үзең сәбәп, без түгел!
Сәтнәр киявең булмаса,
Атам-анам сез түгел!
Әй әткәем, бәхиллә
Сәтнәр белән гомергә!
Шунда гына ризамын
Бергә гомер сөрергә!

Карчык

Күр, күр, явыз, ни сөйли!
Сәтнәр сәбәп барысына!
Киттек әйдә, Михәдәр,
Төкер кызың башына!

Михәдәр

Әх син, Сәтнәр, тотасың
Кызны тамуг утында!
Ә син, усал, юләр кыз,
Саргай да үл шушында!
Менә тукта, йортыма
Үзең чабып килерсең.
Шунда минем нихәтле
Гаделлегем белерсең!
Әйдә инде, карчыгым,
Өйгә китик, яхшысы.
Безнең бүген кыз белән
Сүзләр бетте, ахрысы...

## Карчык

Күзгә яфрак шикелле,
Корып тәмам кибегез!
Шунда череп беткәнче
Этчә газап чигегез!

---

Каргап, оршып китteләр,
Бу ике карт аңгыра.
Урам буйлап карчыгың
Зәһәр сүзләр яудыра.
Кояш батты кызарып,
Оялу сиздe, күрәсең.
Аһ, дип, Сәтнәр әнкәсе
Җыйды өстәл тирәсен...

## 14. ДҮРТ ҮЛЕМ

Авыр эшләр соңыннан
Бигрәк каты йоклата.
Силби халкын тирбәтә
Татлы йокы төн ката.
Йоклый бөтен кешеләр,
Кара урман тын тора.
Кайчак шаян җил генә
Уятыйм, диеп, сызгыра.
Килеп чыкты урманнан
Пар ат җиккән бер арба.
Тагын килеп кушылды
Бер җиңел йөк моңарга.
Шыпырт кына киттеләр,
Кемнәр икән ул анда?
...Йөрәк өзгеч бер тавыш.
...Берәү чаба урамда.
Шыгыр-шыгыр арбалар
Кире якка юл алды, —
Тәгәрәшеп, урманга
Кереп китте, югалды...

---

Урам шаулый, халык күп,
Инде сүз дә таралган.

Берәү шунда кычкыра:
— Михәдәрләр таланган!
Бар да Тури-гаскача
Чатыр-чотыр чабалар.
— Ни булды да ни булды?—
Сораштырып баралар.
— Михәдәрне басканнар!
Бер нәрсәсе калмаган!
Җир йоткыры караклар,
Курыкмыйлар алладан!
Михәдәрне, карчыкны
Шул караклар үтергән!
Шулар алдап әчерткәч,
Җиде ялчы исергән!
Ишетеп карчык тавышын,
Сәтнәр шунда йөгергән.
Балта белән башына
Карак чабып өлгергән!
Үлгән мескен Михәдәр,
Малы-милке калмаган!
Аңсыз-башсыз караклар!
Курыкмыйлар алладан!

---

Бетте мескен Сәтнәр дә
Канлы үткен балтадан.
Силби авылы кайчан да
Мондый хәлгә калмаган!
Мескен Нарспи күзендә
Бер дым да юк — яшь кебек.
Әткәсенең йортында
Басып тора, таш кебек.
Тирмән ташы дыр да дыр
Йөрәк өстен кубара.
Тирмән ташы астында
Йөрәк ярыла шул ара...

Ах!.. Ярылып китте дә
Җиргә екты чибәрне...
Мескен аңга килде дә
Үкереп елап җибәрде:
— Әй син, әткәй, син, әнкәй!
Ник соң мине таптыгыз?
Якты дөнья өстендә
Кайгы-зарга аттыгыз?
Әй бер аллам, кадирем,
Җан биреп тә чикләдең!
Мескен яшь-яшь башыма
Бәхет насыйп итмәдең!
Әй җанкаем, яшь башым,
Нигә яшьләй сулдың син?
Бөтен дөнья алдында
Нигә артык булдың син?
Елый-елый кырлата
Китте Нарспи соңыннан.
Барды киндер кырыннан,
Барды иркен болыннан...
Авыл халкы, артыннан
Карап калды, кызганып.
Төнгә чаклы шул хәлне
Сөйләделәр сызланып...

---

Иртәгесен иртәнчәк
Чуваш кырга бармады;
Атна көне булганга
Эшкә кул да салмады.
Әүвәлгедәй кызлар да
Әйлән-бәйлән җыймады.
Уйнап-биеп җырларга
Егетләр дә кыймады.
Төрле җирдә карт-коры,
Киңәш-уңаш коралар.

Михәдәрнең йорт-җирен
Сатыйк, диеп торалар.
Нарспи кайда икән, дип,
Эзләр өчен киттеләр.
Михәдәрне, карчыкны
Күмәр өчен килделәр.
Ах, нинди зур каберлек!
Өч үлек җан, өч мәнә...
Сәтнәр имән төбендә,
Яткан чирәм өстенә...

---

Бөтен авыл, төш узгач,
Бот чаба да шакката.
Нарспи гәүдәсен табып,
Берни белми, баш вата.
Эзләгәннәр кайттылар,
Атны куып, ашыгып,—
Талга киндер бау белән
Үлгән, диләр, асылып...
Шунда, үлгән урынында,
Кызны гүргә салдылар.
Кабер янын тирәләп,
Читән тотып алдылар...
Кояш батты, кич булды,
Чуваш тала йокыга.
Кояш чыкты, көн булды,
Чуваш эшкә тотына.
Ләкин безнең Нарспига
Мәңгелеккә кич булды.
Гомер кысан кабердә,
Кайгы-зарга чик булды.

---

Шулай үтте тормышы,
Шулай бетте яшьлеге.

Әрәм итте кешенең
Әрәм малга хаслыгы.
Күрде якты дөньяны,
Пүлех-тәңре яраткач.
Үсеп җитте «кызым» дип,
Ата-анасы җан аткач.
Пүлех-тәңре кодрәте
Кызны аңлы ясады.
Аның башын, ниһаять,
Ата-анасы ашады...
Ятты кысан кабергә,
Исеме калды авылда.
Аның моңлы җырлары
Тора халык аңында.
Силби халкы мескенне
Истә тота хәзер дә,
Яңгыр яумый торганда,
Сулар сибә кабергә.

0652.

ЭЧТӘЛЕК

К. Иванов һәм аның «Нарспи» поэмасы . . . 3

1. Силби авылында . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
2. Гүзәл кыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
3. Симек киче . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
4. Туй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 27
5. Багучы янында . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
6. Качу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
7. Ике туй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
8. Хушылкада . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
9. Симек үткәч . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
10. Нарспи эше . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
11. Силбидә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62
12. Урманда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 65
13. Ата-ана . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 69
14. Дүрт үлем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77

*Константин Иванов*

*НАРСПИ*

(на тат. языке)

Художество редакторы *Э. Е. Дьячкова*

Техник редакторы *Р. С. Нәбиуллина*

Корректоры *Л. Х. Шәйнурова*

Наборга бирелде 29|XI-1957 ел. Басарга кул куелды 15|V-1958 ел.
Кәгазь форматы 70 × 92[1]/[32]. Учет-изд. таб. 3,41 + рәсеме 0,03 табак.
Басма табак 2,62 (3,07) + рәсеме 0,06 (0,07) табак. Табакта 63.100 хәреф. Заказ № 0453. Тираж 4000. Бәясе 2 сум 35 тиен.

ТАССР Культура Министрлыгының Татполиграф типографиясе.
Казан, Мисләвский ур., йорт № 9.